РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
422750, село Большая Атня,
улица Ш.Марджани,
дом 6

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы,
6 нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» 01 2026 ел. № 48

**Әтнә муниципаль районында 2026 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортта торак урыннары хуҗалары өчен торак бинаны тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын раслау турында.**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 маддәсенең 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 06 апрелендәге 213/пр номерлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннары хуҗалары өчен торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләрне раслау, торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында»гы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРА:

1. 2026 елга Әтнә муниципаль районында күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак биналар хуҗалары өчен торак бинаны тоту өчен түләү күләменең чик индексын алдагы күләмендә расларга:

01.01.2026 – 30.09.2026 ел. – 1,7% күләмендә;

01.10.2026 – 31.12.2026 ел. – 13,4% күләмендә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (https://atnya.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов